КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 28 гыйнвар г.Казань № 67

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында» 2022 ел, 30 май, 505 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында» 2022 ел, 30 май, 505 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта:

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«алына торган җир кишәрлегенең һәм Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлегенең базар кыйммәтен бәяләгәннән соң 30 көн эчендә, Татарстанның юл-транспорт идарәсе белән берлектә, җир кишәрлекләрен алышу шартнамәсен (алга таба – шартнамә) әзерләүне һәм аны алына торган җир кишәрлеге милекчесенә җибәрүне;»;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«шартнамә төзүне;»;

сигезенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

унынчы абзацта «килешү» сүзен «шартнамә» сүзенә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин